**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1459**
**25.03.2020**

Башкарма комитет резерв фондының
бюджет ассигнованиеләреннән
файдалану тәртибе турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

COVID-2019 китереп чыгарган яңа коронавирус инфекциясе таралуга бәйле рәвештә югары әзерлек режимын тәэмин итү максатында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 87 статьясы, шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М :

1. Башкарма комитетның 2017 елның 9 июнендәге 3528 номерлы карары белән расланган Башкарма комитет резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктчаны өстәргә:

«5) түбәндәгеләргә бәйле күздә тотылмаган чыгымнарны тәэмин итүгә:

- Яр Чаллы шәһәрендә кешеләр тормышына һәм (яки) сәламәтлегенә куркыныч тудыручы йогышлы авыруларның таралуын профилактикалау;

- Яр Чаллы шәһәрендә кешеләр тормышына һәм (яки) сәламәтлегенә куркыныч тудыручы йогышлы авырулар таралу нәтиҗәләрен бетерү.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 6.1 пунктны өстәргә:

«6.1. Башкарма комитетның Яр Чаллы шәһәрендә кешеләр тормышына һәм (яки) сәламәтлегенә куркыныч тудыручы йогышлы авырулар таралуны профилактикалау һәм бетерү мәсьәләләрен координацияләүче (контрольдә тотучы, кураторлык итүче) вазыйфаи затлары, Башкарма комитетның вазыйфаи затлары арасында вазыйфаи бурычларны бүлү турында боерыгы нигезендә, резерв фонды акчаларыннан файдалану турында Башкарма комитет карарын әзерләү өчен, финанс идарәсенә резерв фондыннан бүлеп бирү өчен кирәкле акча күләмен һәм (яки) атап үтелгән хәлләр килеп чыгу фактын раслаучы түбәндәге документларны җибәрә:

1) Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең приказлары һәм башка актлары;

2) муниципаль хокукый актлар;

3) муниципаль контрактлар (килешүләр);

4) Яр Чаллы шәһәрендә кешеләр тормышына һәм (яки) сәламәтлегенә куркыныч тудыручы йогышлы авырулар таралуны профилактикалау һәм (яисә) бетерү мәсьәләләрен карап тикшерә торган комиссияләр, эшче төркемнәр, штаб беркетмәләре.».

3) 7 пунктның икенче абзацында «3,4» цифрларыннан соң «5» цифрын өстәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов